КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 3 июнь г.Казань № 684

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы турында» 2004 ел, 10 ноябрь, 480 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы турында» 2004 ел, 10 ноябрь, 480 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 ел, 14 июнь, 265 нче; 2005 ел, 8 сентябрь, 442 нче; 2006 ел, 30 гыйнвар, 33 нче; 2007 ел, 29 гыйнвар, 22 нче; 2007 ел, 5 март, 70 нче; 2008 ел, 4 февраль, 61 нче; 2009 ел, 9 сентябрь, 628 нче; 2009 ел, 18 декабрь, 860 нчы; 2013 ел, 4 март, 144 нче; 2016 ел, 20 февраль, 106 нчы; 2017 ел, 3 июнь, 335 нче; 2018 ел, 1 сентябрь, 742 нче; 2020 ел, 30 октябрь, 976 нчы; 2021 ел, 21 июль, 630 нчы; 2021 ел, 15 сентябрь, 877 нче, 2021 ел, 30 декабрь, 1355 нче, 2023 ел, 20 февраль, 162 нче, 2023 ел, 21 март, 308 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы көчләре һәм чаралары исемлеге, составы һәм структурасы;»;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтүнең һәм бетерүнең территориаль ярдәмче системасы эшләвен тәэмин итү буенча республика башкарма хакимият органнары исемлеге һәм аларның функцияләре.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе турындагы нигезләмәдә:

8 пунктның икенче абзацында татар текстында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

8[1] пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

10 пунктта «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

12 пунктның өченче абзацында «һәм гражданнар оборонасы» сүзләрен төшереп калдырырга;

24[3] пунктта «югары әзерлектәге яисә» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе турында нигезләмәдә:

3 бүлекнең уникенче абзацында «башкарма хакимият органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр, крестьян (фермер) хуҗалыклары, барлык оештыру-хокукый рәвешләренә һәм милек рәвешләренә бәйсез рәвештә Татарстан Республикасының башка юридик затлары» сүзләрен төшереп калдырырга;

6 бүлекнең кырыгынчы абзацында «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары» сүзләрен «Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү территориаль ярдәмче системасы көчләре һәм чаралары составы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы көчләре һәм чаралары исемлеге, составы һәм структурасы»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль ярдәмче системасы эшләвен тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары исемлеге һәм аларның функцияләренең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтүнең һәм бетерүнең территориаль ярдәмче системасы эшләвен тәэмин итү буенча республика башкарма хакимият органнары исемлеге һәм аларның функцияләре».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин